КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 12 апрель г.Казань № 222

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче, 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы, 2010 ел, 9 апрель, 253 нче, 2010 ел, 9 июнь, 454 нче, 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 21 февраль, 125 нче, 2011 ел, 25 март, 220 нче, 2011 ел, 13 апрель, 291 нче, 2011 ел, 29 июль, 613 нче, 2011 ел, 13 август, 674 нче, 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2013 ел, 9 февраль, 80 нче, 2013 ел, 14 март, 163 нче, 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы, 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы, 2014 ел, 5 февраль, 64 нче, 2014 ел, 29 март, 201 нче, 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче, 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы, 2015 ел, 3 июнь, 401 нче, 2015 ел, 20 август, 610 нчы, 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче, 2016 ел, 26 февраль, 121 нче, 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче, 2017 ел, 9 февраль, 74 нче, 2017 ел, 10 июль, 468 нче, 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы, 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы, 2018 ел, 29 март, 185 нче, 2018 ел, 4 май, 317 нче, 2018 ел, 27 июнь, 523 нче, 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы, 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы, 2019 ел, 4 апрель, 270 нче, 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы, 2020 ел, 26 март, 220 нче, 2020 ел, 25 май, 424 нче, 2020 ел, 26 август, 744 нче, 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче, 2021 ел, 4 май, 306 нчы, 2021 ел,

6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы, 2022 ел, 9 июль, 661 нче, 2022 ел, 6 сентябрь, 964 нче, 2022 ел, 16 ноябрь, 1218 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1483 нче, 2023 ел, 14 апрель, 462 нче, 2023 ел, 05 август, 946 нчы, 2023 ел, 06 октябрь, 1252 нче, 2023 ел, 28 декабрь, 1712 нче, 2024 ел, 10 май, 316 нчы, 2024 ел, 06 август, 623 нче, 2024 ел, 04 сентябрь, 724 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

«3.3. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә һәм әлеге Нигезләмәнең 3.1 һәм 3.2 пунктлары нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.3.1. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә:

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау буенча төп юнәлешләрне билгеләүдә катнаша;

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше өлкәсендә федераль сәясәтне гамәлгә ашыруда катнаша;

үз вәкаләтләре чикләрендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актлары проектларын законнар белән билгеләнгән тәртиптә әзерли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә, шулай ук аларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә норматив хокукый актлар, инструктив-методик документлар әзерли һәм кабул итә;

республика башкарма хакимиятенең башка органнары белән берлектә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча башка норматив хокукый актлар әзерли һәм аларны тормышка ашыра;

хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын икътисадый бәяләүне, Татарстан Республикасы территориясен экологик паспортлаштыруны гамәлгә ашыруны оештыра;

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проектын эшләгәндә, Татарстан Республикасы бюджетын үтәүне оештыруда һәм үтәүдә катнаша;

территориаль планлаштыру документларын карауда Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә катнаша;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма хакимиятнең федераль органы белән килештереп, Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектлары булган очракта Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохиттә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләү, һәм (яки) әйләнә-тирә мохиттә тупланган зыянны бетерү, ә алар булмаганда - хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яки) киметү буенча башка чараларны гамәлгә ашыру, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларын рациональ

файдалану һәм яңадан торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү эшләрен оештыру чаралары планын раслый;

үз компетенциясе чикләрендә экологик нәтиҗәлелекне арттыру программаларын карауда катнаша;

вәкаләтләре чикләрендә әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклый;

вәкаләтләре чикләрендә әйләнә-тирә мохиткә җыелган зыянны бетерүне оештыра;

законнар нигезендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.3.2. Әйләнә-тирә мохитне мониторинглау өлкәсендә:

үз вәкаләтләре чикләрендә әйләнә-тирә мохитне мониторинглау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары проектларын эшли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;

Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) бердәм системасының өлеше булган Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтүнең территориаль системасын булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү хокукы белән дәүләт экология мониторингын (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын) гамәлгә ашыруда катнаша;

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитнең торышы турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүдә катнаша;

атмосфера һавасының дәүләт мониторингын оештыруда һәм уздыруда катнаша.

3.3.3. Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә:

Татарстан Республикасы территориясендә атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт сәясәте уздыруда катнаша;

федераль законнар нигезендә атмосфера һавасы саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актлары проектларын законнар белән билгеләнгән тәртиптә әзерли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә, шулай ук аларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

билгеләнгән тәртиптә атмосфера һавасын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны киметү, аларны ягу атмосфера һавасын пычратуга китергән нефть продуктларыннан һәм ягулыкның башка төрләреннән файдалануны кыскарту максатларында, ягулыкның экологик яктан куркынычсыз төрләрен һәм башка энергия чыганакларын җитештерүне һәм куллануны стимуллаштыра;

транспорт һәм башка хәрәкәтләнү чараларын эксплуатацияләгәндә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны киметү чараларын күрә;

атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларны киметү максатларында торак пунктларда, ял һәм туризм урыннарында, махсус сакланылучы табигать территорияләрендә транспорт һәм башка хәрәкәтләнү чараларының керүенә һәм хәрәкәт итүенә чикләүләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыра;

атмосфера һавасының пычрануы аркасында кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы гадәттән тыш хәлләрдә халыкны яклау чараларын эшләүдә һәм үткәрүдә катнаша;

уңайсыз метеорологик шартлар чорында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны җайга салу эшен оештыра;

атмосфера һавасының торышы, аның пычрануы һәм атмосфера һавасының сыйфатын яхшырту программаларын үтәү һәм тиешле чаралар турында халыкка хәбәр итә;

үз компетенциясе чикләрендә атмосфера һавасын саклау өлкәсендә физик һәм юридик затлар эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы территориясендә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгару күләменең яисә массасының максатчан күрсәткечләрен һәм аларны киметү срокларының билгели;

үз компетенциясе чикләрендә атмосфера һавасын саклау буенча Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка гамәлләрне тормышка ашыра.

3.3.4. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә:

катнаша:

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашырганда барлыкка килгән табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чараларын үткәрүдә;

республика башкарма хакимият органнары эшчәнлегедә һәм җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүнең комплекслы системасын булдырганда циркуляр икътисад принципларын кертү мәсьәләсе буенча оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмалар белән хезмәттәшлек итә;

түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

җитештерүчеләр белән I һәм II класслы куркынычлык калдыкларын, товарларны куллану һәм товарлар төргәкләре калдыкларын аерым туплау һәм җыю буенча төзелгән килешүләр кысаларында чаралар оештыруны;

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш иткәндә экологик иминлекне тәэмин итү мәсьәләләре буенча оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне;

җитештерү һәм куллану калдыкларын эшкәртүне, утильләштерүне, зарарсызландыруны гамәлгә ашыра торган җитештерү-техник комплексларны техник коралландыруны, модернизацияләүне оештыру һәм стимуллаштыру мәсьәләләре буенча оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итүне.

3.3.5. Радиация куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә:

радиация куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар проектларын эшләүдә катнаша;

радиация авариясе килеп чыгу куркынычы янаган очракта оператив чараларны оештыруда һәм уздыруда үз вәкаләтләре чикләрендә катнаша;

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбенә алу һәм тикшереп тору системасы белән идарә итү органы функцияләрен башкара.

вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы территориясендә радиация торышын тикшереп торуны оештыра;

радиация куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру һәм яклау һәм дәүләт мәнфәгатьләрен үтәү өчен шартлар тудыруда катнаша;

вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы территориясендә атом-төш җайланмаларын, радиация чыганакларын һәм атом-төш материалларын һәм радиоактив матдәләрне саклау пунктларын, федераль милектәге йә федераль яисә төбәкара әһәмияткә ия радиоактив калдыкларны саклау, саклау пунктларын, саклагычларын урнаштыру урыны турындагы тәкъдимнәрне килештерүдә, шулай ук Татарстан Республикасы милкендәге радиация чыганакларын, радиоактив матдәләрне тиешле территорияләрдә урнаштыру һәм кораллау турындагы карарлар әзерләүдә катнаша.

3.3.6. Экология экспертизасы өлкәсендә:

Татарстан Республикасының экологик, социаль һәм икътисадый шартлары үзенчәлекләрен исәпкә алып, төбәк дәрәҗәсендәге объектларга экология экспертизасы өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын эшли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;

төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыруны һәм уздыруны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра;

халыкка алдан билгеләп куелган һәм үткәрелә торган экологик экспертизалар һәм аларның нәтиҗәләре турында хәбәр итә;

экология экспертизасы өлкәсендә Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында, алар билгеләнгән очракта максатчан фаразлау күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылыкны, тапшырылган вәкаләтләр мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларның нөсхәләрен билгеләнгән рәвештә федераль вәкаләтле органга үз вакытында тапшыруны тәэмин итә;

тиешле органнардан аларны тормышка ашыру Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә әйләнә-тирә мохиткә турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясарга мөмкин булган экология экспертизасы объектлары турында мәгълүмат ала һәм күрсәтелгән мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына экология экспертизасы объектларына дәүләт экология экспертизасы эксперт комиссияләре утырышларында күзәтүчеләр сыйфатында катнашу өчен экспертлар юллау турында тәкъдимнәр кертә, бу объектларны Татарстан Республикасы территориясендә реализацияләгән очракта һәм Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә Россия Федерациясенең башка субъекты тарафыннан билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек йогынтысы булган очракта.

3.3.7. Планлаштырылган эшчәнлекне бәяләү өлкәсендә:

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый алган төбәк әһәмиятендәге объектларны урнаштырганда, Татарстан

Республикасы территориясендә төбәк әһәмиятендәге объектларны урнаштырырга планлаштыруга бәйле рәвештә махсус файдалану шартлары билгеләнгән зоналарны билгеләгәндә мәнфәгатьләрне саклау максатларында, Россия Федерациясе субъектларын территориаль планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы белән уртак чикләре булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларын территориаль планлаштыру схемалары проектларын килештерә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен территориаль планлаштыру документлары проектларын төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләренә урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларның мөмкин булган тискәре йогынтысына кагылышлы өлешендә килештерә, шулай ук тиешле җирлек, шәһәр округы территориясендә атмосфера һавасын саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә атмосфера һавасын пычратуның җыелма исәпләүләре уздырылган очракта, урнаштыру өчен планлаштырыла торган, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган һәм атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлау чыганаклары урнашкан объектларның атмосфера һавасы сыйфатына тискәре йогынты ясау мөмкинлеге өлешендә җирлекнең, шәһәр округының генераль планнары проектларын килештерә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен территориаль планлаштыру документлары проектларының экологик вәзгыятьне тотрыкландыру һәм яхшырту чараларын гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасын территориаль планлаштыруның расланган схемасы белән туры килү-килмәвенә тәкъдимнәр кертә;

үз компетенциясе чикләрендә территорияне планлаштыру документларын (территорияләрне планлаштыру проектларын) килештерүдә катнаша;

билгеләнгән тәртиптә комплекслы үсәргә тиешле территорияләр чикләрен, шулай ук территорияне комплекслы үстерү турында карарлар проектларын килештерүдә катнаша.

3.3.8. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә нормага салу тармагында:

хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектлары (федераль дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларыннан тыш) өчен әйләнә-тирә мохиткә рөхсәт ителә торган йогынтыны нормага салу эшләрен оештыра һәм үткәрә;

билгеләнгән тәртиптә әйләнә-тирә мохит сыйфаты нормативларын билгели;

табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең территориаль органы тәкъдиме буенча атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларның мөмкин нормативларына этаплап ирешү срокларын раслый;

имин булмаган метеошартлар чорында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларны киметү чаралары планнарын килештерә;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә нормага салу системасын формалаштыруга һәм нәтиҗәле файдалануга юнәлдерелгән норматив хокукый актларны камилләштерү һәм үстерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

төбәк дәүләт экология контроленә (күзәтчелегенә) булырга тиешле II категориягә кертелгән объектларда хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек башкаручы

юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан бирелә торган әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау турында декларацияләр кабул итүне гамәлгә ашыра.

3.3.9. Татарстан Республикасы территориясендә су ресурсларын саклау, суларның тискәре йогынтысын булдырмау өлкәсендә:

үз компетенциясе чикләрендә су объектларын саклауга һәм алардан файдалануга күзәтчелек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары проектларын әзерли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;

Татарстан Республикасы милкендәге су объектларын саклау чараларын гамәлгә ашыра;

бирелгән вәкаләтләр чикләрендә федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларын яисә аларның өлешләрен саклау чараларын гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе Су кодексының $67^1$ статьясында суларның тискәре йогынтысын булдырмау һәм аның зыяннарын бетерү буенча каралган чараларны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларыннан яисә аларның өлешләреннән файдалану һәм аларны саклау буенча Татарстан Республикасы программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

агып төшүче суларны агызу планын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезендә килештерә.

3.3.10. Җир ресурсларын саклау өлкәсендә:

үз вәкаләтләре чикләрендә  җир ресурсларын саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары проектларын һәм башка норматив хокукый актларын эшләүдә катнаша;

билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү процедурасында катнаша;

федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеге булдыруга рөхсәт проектын кызыксынган республика башкарма хакимияте органнарына бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә килештерүгә җибәрә;

«Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 10 өлешендә каралган очракларда  дәүләт хакимияте органнары һәм федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеге булдыруга рөхсәт проекты буенча кисәтүләр юллаган (яисә) җирле үзидарә органнары катнашында килештерү комиссиясе төзү турында карар кабул итә;

«Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 10 өлешендә каралган очракларда килештерү комиссиясе эшен оештыра;

федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеге булдыруга рөхсәт проектын килештерә;

«Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 10 өлешнең 1 һәм 2 пунктларында каралган очракларыннан тыш, федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеге төзүгә рөхсәт бирә яисә, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, мондый рөхсәт бирүдән баш тарта.

3.3.11. Су ресурсларыннан файдалану һәм судан файдалануны җайга салу өлкәсендә:

Татарстан Республикасы милкендәге су объектлары белән эш итү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларыннан яисә аларның өлешләреннән файдалану һәм аларны саклау буенча Татарстан Республикасы программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

Татарстан Республикасы милкендәге су объектларыннан файдаланган өчен түләү ставкаларын билгеләү тәртибенең һәм мондый түләүне исәпләү һәм алу тәртибенең проектларын әзерли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертә;

бассейн советлары эшчәнлегендә катнаша;

Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының эш режимнарын билгеләү мәсьәләләре буенча Су ресурслары федераль агентлыгының Идел-Кама каскады сусаклагычларының эш режимнарын җайга салу буенча ведомствоара эшче төркем эшендә катнаша;

су объектларын яисә аларның өлешләрен, шул исәптән федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, муниципаль берәмлекләр милкендәге объектлардан тыш, Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләре кысаларында су объектларын файдалануга бирү турындагы килешүләр, карарлар нигезендә файдалануга бирә;

су объекты акваториясеннән файдалану өлешендә судан файдалану шартнамәсен төзү хокукын алуга аукционнар уздыруны оештыра;

Министрлык тарафыннан төзелгән су куллану шартнамәләре буенча су объектларыннан файдаланган өчен түләүнең администраторы вәкаләтләрен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылма һәлакәте аркасында физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү өлешендә гидротехник корылмаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша;

җир асты сулары ятмаларының расланган запаслары базасында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү чыганакларын резервлау өчен материаллар әзерләүдә катнаша;

Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарын билгеләү, үзгәртү һәм туктату турында карарлар кабул итү.

3.3.12. Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә:

Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасының нефть чыгару предприятиеләре тарафыннан планлаштырыла торган нефть чыгару күләме, эксплуатацияләү һәм эзләү-разведкалау бораулавы турында мәгълүмат әзерли;

Россия Федерациясенең җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, минераль-чимал базасын үстерү һәм үзләштерү буенча дәүләт программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу, шулай ук минераль-чимал базасын үстерү һәм аннан файдалану буенча территориаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр әзерли;

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү эшләрен башкаруга дәүләт контрактларын төзүне гамәлгә ашыра;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү тәртибен билгеләүдә катнаша;

җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү федераль органына яки аның территориаль органына җир асты байлыклары кишәрлекләрен җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен, бердәм лицензия буенча гамәлгә ашырыла торган җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен яисә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертү турында, җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү шартлары һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр шартлары турында тәкъдимнәр кертә;

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-I номерлы Россия Федерациясе Законының $10^1$ статьясындагы беренче өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү турындагы заявкаларны карап тикшерү өчен җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү федераль органы яисә аның территориаль органы тарафыннан төзелә торган комиссия эшендә катнаша;

файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмаган гомумтаралган файдалы

казылмалар запасларына һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасын үткәрә;

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-I номерлы Россия Федерациясе Законының $23^2$ статьясындагы өченче өлешендә каралган авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүгә проект документацияләрен, шулай ук әлеге проект документациясенә кертелә торган үзгәрешләрне килештерү буенча җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү федераль органы тарафыннан оештырыла торган комиссия эшендә катнаша;

Татарстан Республикасы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану территориаль агентлыгы белән берлектә, төзеләчәк йорт җирләре астында файдалы казылмаларның һәм җир асты суларының булмавы яки файдалы казылмалар булган мәйданнарда йортлар төзүне гамәлгә ашыруга рөхсәтләр бирү турында бәяләмәләр әзерләүдә катнаша;

җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз алып баруга дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруда һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның җир асты байлыклары турындагы законнарны, шулай ук җир асты байлыкларын саклау буенча билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларны һәм таләпләрне үтәвендә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары белән хезмәттәшлек итә;

Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларыннан файдалануның төп юнәлешләрен билгеләүдә катнаша;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләүне гамәлгә ашыра;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә файдалануга тапшырылган җир асты байлыклары кишәрлекләренең дәүләт реестрын алып бару өчен белешмәләрдән файдалануга лицензияләр дә һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр дә бирүне гамәлгә ашыра;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга билгеләнгән тәртиптә лицензия бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренең һәркайсы буенча җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләү ставкасының конкрет күләмен билгели;

Татарстан Республикасының минераль-чимал потенциалына икътисадый анализ һәм фараз ясауны гамәлгә ашыра;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү федераль органы яки аның территориаль органы белән килештереп, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлекләрен әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондын булдыруны һәм алып баруны гамәлгә ашыра;

җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү федераль органы яки аның территориаль органнары вәкилләре составка кертелә торган гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын ачу фактын билгеләү комиссиясен төзи;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары һәм чыганаклары запасларының һәм кадастрының республика балансын төзи һәм алып бара, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган корылмалар төзү өчен файдаланыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләрен исәпкә ала;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү һәм аукционнар комиссияләре составлары турында карарлар кабул итә;

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 23 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 6 статьясында каралган җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре буенча җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану шартларын әзерләүне гамәлгә ашыра;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү турында карарлар кабул итә;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыклары кишәрлекләренең дәүләт реестрында реестр язуларын төзү яки үзгәртү өчен мәгълүматлар һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга законнарда билгеләнгән тәртиптә лицензияләр бирүне гамәлгә ашыра;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын (радиоактив калдыкларны, I – IV куркынычлылык классларындагы җитештерү һәм куллану калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклагычлардан тыш) төзүнең һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле тау эшләнмәләрен, бораулау скважиналарын һәм башка корылмаларны бетерүнең һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерүне гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән очракларда, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата бүлеп бирелгән тау кишәрлегенең төгәлләштерелгән чикләрен (бүлеп бирелгән тау кишәрлеге акты һәм график кушымталар) раслый торган документларны рәсмиләштерүне гамәлгә ашыра;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату (шул исәптән вакытыннан алда туктату), җир асты байлыкларын файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм җир асты байлыкларын файдалану хокукын чикләү тәртибен билгели;

чыгарганда ятмаларны эшкәртү буенча кабул ителгән схемага һәм технологиягә технологик бәйле булган, проект документациясе составында расланган нормативлар күләменнән артып киткән гомумтаралган файдалы казылмаларны югалту нормативларын килештерә;

үз компетенциясе чикләрендә җир асты байлыкларын геологик-геофизик өйрәнүнең торышына мониторинг үткәрү һәм файдалы казылмалар ятмаларын үзләштерү эшләрен оештыруны тәэмин итә;

Татарстан Республикасы территориясендә геологик мохит мониторингын алып бару эшләрен оештыруны, республика башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга һәм башка хуҗалык эшчәнлеге субъектларына геологик мохит торышына тискәре йогынты ясый торган факторлар турында, шулай ук геологик мохиткә үзгәреш кертүгә бәйле мөмкин булган гадәттән тыш хәлләр турында хәбәр бирүне тәэмин итә;

фәнни, мәдәни, эстетик, санитария-савыктыру һәм башка әһәмияткә ия геологик объектларны махсус саклана торган табигать территорияләренә кертү турында тәкъдимнәр әзерли;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыклары турындагы Россия Федерациясе законнарын бозу аркасында җир асты байлыкларына китерелгән зыян күләмен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләп чыгаруны гамәлгә ашыра.

3.3.13. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) өлкәсендә:

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрнең үтәлешенә төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) (федераль дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) тотылырга тиешле булмаган объектларга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән рөхсәт документларындагы таләпләрне кертеп) гамәлгә ашыра;

төбәк дәүләт геологик контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра;

әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган һәм төбәк дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле объектларның дәүләт исәбен алып бара;

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә контроль (күзәтчелек) чараларын гамәлгә ашыру кысаларында әйләнә-тирә мохит объектларын һәм әйләнә-тирә мохиткә пычраткыч матдәләр чыгару һәм агызу чыганакларын сайлап ала, тикшерә (сыный), аларның пробаларын үлчи;

Министрлыкның Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген), төбәк дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертә;

Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә), төбәк дәүләт геология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле II һәм III категорияләргә кертелгән объектларда хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек башкаручы юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары планының үтәлеше турында хисаплар кабул итүне гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралган очракларда, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне гамәлгә ашыра;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны бозып гамәлгә ашырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне (федераль дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле объектлардан тыш) билгеләнгән тәртиптә чикләү,

туктатып тору һәм (яки) тыю турында таләп белән, шулай ук табигатьне саклау законнарын үтәүне тәэмин итү максатларында билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендәге башка таләпләр белән судка мөрәҗәгать итә;

мәҗбүри таләпләр бозылу аркасында әйләнә-тирә мохиткә салынган зыянны каплау турында дәгъвалар бирә;

үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы территориясендә региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) нәтиҗәсендә алынган мәгълүматны анализлый һәм гомумиләштерә.

3.3.14. Әйләнә-тирә мохитне саклау, экологик тәрбия һәм оештыру-координация, экология-икътисадый эшчәнлек өлкәсендә мәгълүмати-аналитик, методик тәэмин итү өлкәсендә:

түбәндәгеләрдә катнаша:

Татарстан Республикасы территориясендә экологик белем системасын оештыру һәм үстерү һәм экологик культураны булдыру;

экологик бәла-каза зоналарына кертелгән территорияләрне реабилитацияләү программаларын эшләү максатларында әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә тикшеренү эшләре уздыруны оештыру;

билгеләнгән тәртиптә республика башкарма хакимияте органнарын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарын, халыкны республика территориясендә әйләнә-тирә мохитнең торышы турында дөрес мәгълүмат белән тәэмин итә;

экология һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә төбәк һәм федераль мәгълүмат системаларын кертүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итә;

экология һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә цифрлы платформа төзүдә һәм үстерүдә катнаша;

конгресслар, конференцияләр, семинарлар, күргәзмәләр һәм Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә башка чаралар оештыра;

Татарстан Республикасында Экологик иминлек, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссия эшен оештыру, матди-техник һәм мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлекне тәэмин итү өчен, табигатьне саклау программаларын һәм проектларны финанслау өчен инвестицияләр җәлеп итү эшен оештыра;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге җирле үзидарә органнары эшчәнлеген методик тәэмин итүдә катнаша;

халыкны экологик тәрбияләүне һәм дәүләт хакимияте башкарма органнары, мәгариф учреждениеләре, иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләүне оештыра;

Татарстан Республикасында экологик аудитны һәм экологик сертификацияне үстерүне тәэмин итә;

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планы чараларын гамәлгә ашыруны координацияли;

компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы территориясендә оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар эшчәнлегендә катнаша:

экологик иминлекне тәэмин итү,

экологик тәрбия һәм агарту системасын үстерү,

экология программаларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча аерым чараларны гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасында табигатьне саклау билгеләнешендәге эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр базарын үстерүгә ярдәм итә торган тематик күргәзмәләр, семинарлар, өйрәтү курслары һәм башка чаралар уздыруны оештыра;

үз компетенциясе чикләрендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыра;

Табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләүне гамәлгә ашыра;

үз вәкаләтләре чикләрендә мәгълүматны әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны гамәлгә ашыра.

3.3.15. Министрлык эшчәнлеген тәэмин итү өлкәсендә:

республика башкарма хакимият органнары, экология күзәтчелеге, су ресурслары, урман хуҗалыгы, табигатьтән файдалану һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, билгеләнгән тәртиптә чит дәүләтләрнең һәм халыкара оешмаларның дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек итә;

гражданнарны кабул итүне гамәлгә ашыра, гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрен үз вакытында һәм тулысынча карауны тәэмин итә, алар буенча карарлар кабул итә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта җаваплар җибәрә;

Министрлыкны тотуда һәм аңа йөкләнгән вазыйфаларны гамәлгә ашыруда каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче һәм алучы функцияләрен башкара;

законнар нигезендә билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт ихтыяҗлары һәм Министрлык ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне дә кертеп, сатып ала;

үз эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт заказчысы функцияләрен башкара;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финансланырга тиешле табигатьне саклау чараларының еллык программасын төзи һәм аны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга тапшыра;

үз компетенциясе чикләрендә дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрне яклауны тәэмин итә;

Министрлык эшчәнлеге процессында барлыкка килгән архив документларын туплау, саклау, исәпкә алу һәм алардан файдалану эшен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра;

табигать саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның вазыйфаи затлары һәм аерым категорияләре өчен форма киеме үрнәкләрен, аерымлык билгеләрен

эшләүдә билгеләнгән тәртиптә катнаша һәм аларны киеп йөрү һәм форма киемнәре белән тәэмин итү тәртибен раслый;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең, эшләре Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлегенә бәйле булган яки аны алып бару өлкәсенә караган оешмаларның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә, шулай ук бу чараларның методик тәэмин ителешен гамәлгә ашыра;

үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, башка Россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләр, килешүләр һәм башка гавами-хокукый характердагы актлар реестрын алып бара;

ел саен, 1 февральгә кадәр, Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус органга коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында хисап кертә;

3.3.16. Кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә:

тармакны кадрлар белән тәэмин итүнең торышын өйрәнә һәм анализлый;

тармакның башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү һөнәрләре һәм белгечлекләре буенча квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүгә ихтыяҗы фаразын формалаштыра;

хезмәт ресурсларын җәлеп итү һәм аларны тармакта эш белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыра;

Министрлык хезмәткәрләренең һөнәри әзерлеген, яңадан әзерләүне, квалификациясен күтәрүне һәм стажировкасын оештыра.

3.3.17. Террорчылыкка каршы тору өлкәсендә:

террорчылыкка каршы көрәш чараларын гамәлгә ашырганда өйрәнүләр үткәрүдә катнаша;

Министрлыкка беркетелгән объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышына карата таләпләрне үти;

террорчылык чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) бетерү өчен билгеләнгән көчләрне һәм Министрлык чараларын нәтиҗәле файдалануга даими әзерлек хәлендә тотып тора.

3.3.18. Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен (алга таба – учреждениеләр) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән:

учреждениеләр төзү, аларны үзгәртеп оештыру, аларның типларын үзгәртү, аларны бетерү турындагы карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

учреждениеләр эшчәнлегенең учреждение эшчәнлеген бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен бәяли;

хезмәт законнары һәм учреждениеләрнең хезмәт хокукы нормалары бирелгән башка норматив хокукый актлары үтәлешен ведомство контролендә тотуны гамәлгә ашыра;

учреждениеләргә аларның уставларында каралган төп эшчәнлек төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый;

учреждениеләрне гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин